**СОВЕТ**
**МАСАДИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423753, деревня Масады,
ул. Нефтяников ,дом 18 ,
Тел. 3-44-49

**АКТАНЫШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МЭСЭДЕ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423753, Мәсәде авылы,
Нефтяниклар ур.,18 нче йорт.
Тел. 3-44-49

№ 31 22.11.2019ел

РЕШЕНИЕ КАРАР

«Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында»

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Мәсәде авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясына, Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Советы

Карары:

1. Мәсәде авыл җирлеге территориясендә 2020 нче елда, 1 нче төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

Юл эшчәнлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата:

- Мәсәде,Бурсык авылларында юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС салу, грейдлау, кардан чистарту).

Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- янгын җиһазләрен сатып алу;

- торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;;

- җирлек торак пунктында игъланнар тактасы ясау һәм аларны урнаштыру;

- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү.

Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тору;

- Күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү.

Халыкка торак-коммуналь, көнкүреш һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә оештыру:

-урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;

- су чыганакларын лицензияләү.

Халык күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү.

-рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү.

2. Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге гражданнарының авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында җыелу нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Мәсәде авыл җирлеге

Советы башлыгы Мингазетдинова Ф. Р.